КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 28 ноябрь г.Казань № 1073

Татарстан Республикасы Министр-лар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемнәрдәге затларга медицина ярдәме күрсәтүче Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы дәүләт медицина оешмаларының медицина хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен һәм Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемнәрдәге затларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне бирү тәртибен һәм 2020 елда яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемнәрдәге затларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен шәхси медицина оешмаларына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 27 апрель, 340 нчы карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемнәрдәге затларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен

кызыксындыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен һәм Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемнәрдәге затларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 27 апрель, 340 нчы карары белән расланган Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемнәрдәге затларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 19 август, 707 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемнәрдәге затларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен һәм Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемнәрдәге затларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 27 апрель, 340 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 8 сентябрь, 808 нче карары.

2. Бу карарның гамәле 2020 елның 1 ноябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин